Осторма Юмья авыл җирлеге Советы

# КАРАР

16 декабрь, 2025 ел №10

Осторма Юмья авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июнендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Осторма Юмья авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Осторма Юмья авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Осторма Юмья авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июнендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Осторма Юмья авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) (Осторма Юмья авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 ноябрендәге 26 номерлы 2020 елның 21 декабрендәге 14 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 42 номерлы, 2024 елның 11 июнендәге 16 номерлы, 2024 елның 13 августындагы 22 номерлы, 2024 елның 03 декабрендәге 37, 2025 елның 14 июнендәге 14 номерлы номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
| --- | --- |
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 23 201,0 |

б) 3.1 пунктның беренче абзацында «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Осторма Юмья авыл
җирлеге башлыгы С.В. Тимофеев